ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 1 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты 2023 елның 10 ноябренә кадәр әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2187-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Законлылык һәм хокук
тәртибе комитеты
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «яисә электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы йә «Дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда шәхси кабинет (уникаль идентификатор) адресы (алга таба – Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «яисә электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «электрон почта адресын» сүзләреннән соң «йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресын» сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

«$8^1$. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә шәхси чираттан тыш кабул ителү хокукына I, II төркем инвалидлары, инвалид балалар һәм мондый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Шәхси чираттан тыш кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары; хәрби гамәлләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларының, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) кабул итүгә өч яше тулмаган балалар белән килгән гражданнар.

Шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 10 өлештә «9 өлешендәге 1–4 пунктларында» сүзләрен «8[1], 9 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга, «шәхси беренче чиратта» сүзләрен «шәхси чираттан тыш яисә беренче чиратта» сүзләренә алмаштырырга;

г) 12 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 16 статьяның 5 пунктында «электрон почта адресы буенча» сүзләрен «мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4) 20 статьяда:

а) 2 өлештә «яисә электрон почта адресын» сүзләрен «, электрон почта адресын йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «электрон почта адреслары» сүзләреннән соң «йә Бердәм порталдагы шәхси кабинетлар адреслары» сүзләрен өстәргә;

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны гражданнар, гражданнар берләшмәләре, шул исәптән юридик затлар, мөрәҗәгатьләрен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә, гавами әһәмиятле функцияләр башкаручы башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына, «Дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм портал) кулланып, электрон документлар рәвешендә җибәрү һәм күрсәтелгән органнар, оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан мондый мөрәҗәгатьләргә

мөрәҗәгать җибәргән затның шәхси кабинеты (уникаль идентификаторы) адресы буенча Бердәм порталда җаваплар җибәрү мөмкинлегенә карата тәэмин итү, әгәр күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тарафыннан әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр мондый мөмкинлек тәэмин ителмәгән булса, 2025 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон белән гражданнар тарафыннан «Дәүләт хезмәтләре» порталын кулланып мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм мондый мөрәҗәгатьләргә «Дәүләт хезмәтләре» порталында шәхси кабинет (уникаль идентификатор) адресы буенча җаваплар җибәрү мөмкинлеге күздә тотыла. Күрсәтелгән үзгәрешләр 16-ТРЗ номерлы Закон белән җайга салына торган нигезләмәләргә кагыла, моңа бәйле рәвештә республика Законының 4, 16 һәм 20 статьяларына үзгәрешләр кертелә. Шул ук вакытта закон проектында «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны гражданнар, гражданнар берләшмәләре, шул исәптән юридик затлар, мөрәҗәгатьләрен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә, гавами әһәмиятле функцияләр башкаручы башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына, «Дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм портал) кулланып, электрон документлар рәвешендә җибәрү һәм күрсәтелгән органнар, оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан мондый мөрәҗәгатьләргә мөрәҗәгать җибәргән затның шәхси кабинеты (уникаль идентификаторы) адресы буенча Бердәм порталда җаваплар җибәрү мөмкинлегенә карата тәэмин итү, әгәр күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тарафыннан әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр мондый мөмкинлек тәэмин ителмәгән булса, 2025 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла дип билгеләнә.

Моннан тыш, закон проектында шулай ук төгәлләштерә торган характердагы үзгәреш, ягъни 16-ТРЗ номерлы Законның 11 статьясына I, II төркем инвалидлары, шулай ук инвалид балалар һәм мондый балаларны озатып йөрүче затлар өчен дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт учреждениеләрендә һәм муниципаль учреждениеләрдә, гавами әһәмиятле функцияләр башкаручы башка оешмаларда һәм аларның вазыйфаи затларына шәхси чираттан тыш кабул ителү хокукы билгели торган $8^1$ өлеш өстәп кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.